ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2017 Казан ш. № 5-80/тэ

«ТГК-16» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.11.2015 №5-49/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2018 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә һәм, 2018 елга җайга салынулы оешманың план буенча кирәкле тулай табышын тәгаенләп, 2018 елга «ТГК-16» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә дәвамлы тарифларга төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «ТГК-16» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә 2016-2018 елларга тарифлар билгеләү турында» 30.11.2015 № 5-49/тэ карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 29.01.2016 № 5-2/тэ, 16.12.2016 № 5-65/кс карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче

кушымтага, шушы карар кушымтасына туры китерелгән яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2017 № 5-80/тэ карарына кушымта
«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.11.2015 № 5-49/тэ карарына 1 нче кушымта

# "ТГК-16» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә 2016-2018 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Җайга салынулы оешманың, муниципаль берәмлекнең аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Ачы һәм редукция-ләште-релгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 $кг/см^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 $кг/см^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 $кг/см^2$ кадәр | 13,0 $кг/см^2$ югары | |
| 1 | «ТГК-16» ачык акционерлык җәмгыяте | | | | | | | |
| 1.1 | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 1.1.1 | Тоташтыру схемасы буенча дифференциацияләгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | Бер ставкалы тариф, сум/Гкал (магистраль җылылык челтәрләренә тоташтырылган ЕТО-2 кулланучылары өчен) | 01.01.2016 башлап 30.06.2016 кадәр | 670,54 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2016 башлап 31.12.2016 кадәр | 696,90 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2017 башлап 30.06.2017 кадәр | 696,90 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2017 башлап 31.12.2017 кадәр | 1659,32 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 1659,32 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 3053,97 | - | - | - | - | - |
| 1.1.2 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | | | | | | | |

| № п/п | Җайга салынулы оешманың, муниципаль берәмлекнең аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Ачы һәм редукция-ләште-релгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 $кг/см^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 $кг/см^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 $кг/см^2$ кадәр | 13,0 $кг/см^2$ югары | |
| | Бер ставкалы тариф, сум/Гкал (магистраль җылылык челтәрләренә тоташтырылган ЕТО-2 кулланучылары өчен) | 01.01.2016 башлап 30.06.2016 кадәр | 791,24 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2016 башлап 31.12.2016 кадәр | 822,34 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2017 башлап 30.06.2017 кадәр | 822,34 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2017 башлап 31.12.2017 кадәр | 1958,00 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 1958,00 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 3603,69 | - | - | - | - | - |
| 1.1.3 | Тоташтыру схемасы буенча дифференциацияләгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | Бер ставкалы тариф, сум/Гкал (бүлүче җылылык челтәрләренә тоташтырылган ЕТО-2 кулланучылары өчен) | 01.01.2016 башлап 30.06.2016 кадәр | 1 274,80 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2016 башлап 31.12.2016 кадәр | 1 325,64 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2017 башлап 30.06.2017 кадәр | 1194,92 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2017 башлап 31.12.2017 кадәр | 1208,18 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 1208,18 | - | - | - | - | - |

| № п/п | Җайга салынулы оешманың, муниципаль берәмлекнең аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Ачы һәм редукция-ләште-релгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 1258,92 | - | - | - | - | - |
| 1.1.4 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | | | | | | | |
| | Бер ставкалы тариф, сум/Гкал (бүлүче җылылык челтәрләренә тоташтырылган ЕТО-2 кулланучылары өчен) | 01.01.2016 башлап 30.06.2016 кадәр | 1 504,26 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2016 башлап 31.12.2016 кадәр | 1 564,25 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2017 башлап 30.06.2017 кадәр | 1410,00 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2017 башлап 31.12.2017 кадәр | 1425,65 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 1425,65 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 1485,53 | - | - | - | - | -» |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге